**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 август № 581

г. Казань

Юридик затлар атамаларында Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалану тәртибе турында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 54 статьясы нигезендә, юридик затлар атамаларында Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалануны тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Юридик затлар атамаларында «Татарстан Республикасы», «Татарстан» сүзләре, шулай ук алар нигезендә ясалган сүзләр һәм кыскартылмалар Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы рөхсәте белән файдаланыла;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, башка Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары актлары нигезендә гамәлгә куелган юридик затлар, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле һөнәр берлекләре, коммерциягә карамаган оешмалар үзләренең атамаларында «Татарстан Республикасы», «Татарстан» сүзләрен, шулай ук алар нигезендә ясалган сүзләр һәм кыскартылмаларны рөхсәт алмыйча файдалана.

2. Юридик затлар атамаларында Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалануга рөхсәт бирү тәртибе турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) расларга.

3. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга үз атамаларында «Татарстан Республикасы», «Татарстан» дигән сүзләрне һәм алар нигезендә ясалган сүзләр һәм сүзтезмәләрне файдалануга рөхсәт бирү турында» 2004 ел, 12 апрель, 179 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга үз атамаларында «Татарстан Республикасы», «Татарстан» дигән сүзләрне һәм алар нигезендә ясалган сүзләр һәм сүзтезмәләрне файдалануга рөхсәт бирү турында» 2004 ел, 12 апрель, 179 нчы карары

белән расланган Юридик затларга үз атамаларында «Татарстан Республикасы», «Татарстан» дигән сүзләрне һәм алар нигезендә ясалган сүзләр һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылган) файдалануга рөхсәт бирү турындагы гаризаларны карау тәртибе хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2011 ел, 15 октябрь, 852 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 12 апрель, 179 нчы карары белән расланган Юридик затларга үз атамаларында «Татарстан Республикасы», «Татарстан» дигән сүзләрне һәм алар нигезендә ясалган сүзләр һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылган) файдалануга рөхсәт бирү турындагы гаризаларны карау тәртибе хакындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» 2012 ел, 20 февраль, 125 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 ел, 19 август 599 нчы карарының 4 нче пункты.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 август, 581 нче карары белән расланды

Юридик затлар атамаларында Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалануга рөхсәт бирү тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан юридик затлар атамаларында «Татарстан Республикасы», «Татарстан» сүзләрен, шулай ук алар нигезендә ясалган сүзләр һәм кыскартылмаларны файдалануга рөхсәтләр (алга таба – рөхсәт) бирү турындагы гаризаларны карап тикшерү һәм алар буенча карар кабул итү тәртибен билгели.

2. Юридик затны гамәлгә куючы (алга таба – гариза бирүче) вәкаләтле органга рөхсәт бирү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итә.

Рөхсәт бирү турындагы гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

нотариуста таныкланган күчермәләре булмаса, төп нөсхәләрен күрсәтеп, юридик затны гамәлгә кую документлары күчермәләре;

юридик затның әлеге Нигезләмәнең 3 нче пунктында каралган критерийларның берсенә туры килүен раслый торган документлар;

гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ.

3. Юридик зат түбәндәге критерийларның берсенә туры килгән очракларда, Вәкаләтле орган рөхсәт бирү турында карар кабул итә:

юридик зат законнар нигезендә эре салым түләүче булып тора;

юридик зат билгеле бер товар базарында өстенлек иткән урын алып тора;

акционерлык җәмгыятенең тавыш бирүче акцияләренең 25 процентыннан артыгы Татарстан Республикасы милкендә тора;

юридик зат тышкы икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасын дөнья базарында тәкъдим итә.

4. Юридик затның әлеге Нигезләмәнең 3 нче пунктында каралган критерийларның берсенә туры килүе турындагы мәгълүматны раслау максатларында, вәкаләтле орган, әлеге Нигезләмәнең 2 нче пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар кертелгән көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, кирәкле мәгълүматларны дәүләт органнарыннан һәм оешмалардан соратып ала. Соратып алына торган мәгълүматлар вәкаләтле органга законнарда билгеләнгән вакытта бирелә.

5. Вәкаләтле орган әлеге Нигезләмәнең 2 нче пунктында каралган гариза һәм документлар кертелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә рөхсәт бирү турында яки рөхсәт бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә. Күрсәтелгән вакытка вәкаләтле орган әлеге Нигезләмәнең 4 нче пункты нигезендә мәгълүмат сората һәм ала торган вакыт кертелми. Карар Татарстан Республикасы юстиция министры боерыгы рәвешендә рәсмиләштерелә.

6. Вәкаләтле орган тарафыннан рөхсәт бирүдән баш тарту хакында карар кабул ителү өчен әлеге Нигезләмәнең 3 нче пунктында билгеләнгән таләпне үтәмәү нигез булып тора.

7. Кабул ителгән карар турында гариза бирүчегә, әлеге Нигезләмәнең 5 нче пунктында күрсәтелгән боерык күчермәсен теркәп, ул басылып чыккан көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча язма рәвештә хәбәр ителә. Рөхсәт бирүдән баш тарту хакында карар кабул ителгән очракта, хатта әлеге карарның мотивлаштырылган сәбәбе күрсәтелә.

8. Рөхсәтне башка юридик затка бирү рөхсәт ителми.

9. Юридик затның атамасы яки оештыру-хокукый формасы үзгәргән очракта, билгеләнгән тәртиптә бирелгән рөхсәт нигезендә юридик затның атамасында «Татарстан Республикасы», «Татарстан» сүзләрен, шулай ук алар нигезендә ясалган сүзләр һәм сүзтезмәләрне, шул исәптән кыскартылмаларны файдалану хокукы саклана. Әлеге Нигезләмә үз көченә кергәнче гамәлдә булган тәртиптә бирелгән рөхсәтләрнең көче саклана.

---